**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 16 гыйнвар № 9

г. Казань

Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләү турында

Халыкка һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына әйләнә-тирә мохит торышы һәм аны саклау чаралары турында тулы дөрес мәгълүмат бирү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләү турында нигезләмәне;

табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләүдә катнашучылар исемлеген.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына әлеге карар белән расланган Нигезләмә нигезендә табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләүне гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына хисап чорыннан соң килә торган елның 15 апреленә кадәр табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләү өчен компетенцияләренә ярашлы табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында  аналитик мәгълүматны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына тапшырырга, шулай ук федераль дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль

органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Әйләнә-тирә табигый мохит торышы турында еллык дәүләт докладын әзерләү турында» 1994 ел, 24 февраль, 73 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\9.docx